ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 4 сентябре Олы Ачасыр авылы № 22

Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 13 октябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Олы Ачасыр авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Ирекле янгын күзәтчелеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 445-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 13 октябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Олы Ачасыр авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертелергә:

- 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Әлеге нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар «Ирекле янгын күзәтчелеге турында»гы 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль законндагы кебек үк мәгънәдә кулланыла.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл җирлеге
башлыгы урынбасары М.Г. Гатиятуллин